**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«18» декабрь 2024 ел** **№ 281**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат муниципаль мөлкәт исемлеген һәм арендага бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 31 октябрендәге 67 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 24.07.2007 ел, №209-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге өченче зат хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм инфраструктура барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару, Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү, шулай ук мондый мөлкәтне арендага бирү тәртибен тәртибен раслау турында" 2024 елның 15 ноябрендәге 273 номерлы карары, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, аренда шартларында муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат муниципаль районы Советының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәт исемлеген һәм арендага бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 31 октябрендәге 67 номерлы карары белән расланган 1нче кушымтага (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр кертергә аны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак - коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев